**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 69/1 “ 25 ” сентябрь 2017 ел

Урсай авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 131 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Урсай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Урсай авылы башкарма комитетының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Урсай авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 68 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Урсай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Урсай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
1. Юл эшчәнлегенә карата автомобиль җирле әһәмияттәге юлларны, Урсай авылы җирлекнең торак пунктлары чикләрендә карап:
-таш салу һәм юлларны тигезләү,
-чокырларны ямау,
-кыш айларында кардаң чистарту;

2. Зиратларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту:
- Урсай авылы зиратының коймаларын алыштыруга;

3. Авыл җирлеге биләмәсендә халыкны су белән тәэмин итү өчен:
- су линияләрен ремонтлау һәм төзек хәлдә тоту,
- артезиан скважинасына насос сатып алу ;

4. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру:
-урам утларын карау һәм төзек хәлдә тоту;

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның "Маяк" газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: И.А.Абдуллин